**Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге составына керүче Татар Сарсазы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

21 ноябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советының 2019 елның 4 октябрендәге 122 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, 2023 елның 21 ноябрендә 14.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Татар Сарсазы авылы гражданнар җыенында «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Песәй авылы җирлегенең Татар Сарсазы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, карамагында балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия армиясенә хәрби хезмәткә чакырылганнардан 500 сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы:

1. вак таш сатып алу (китерү, тигезләү);
2. кышкы чорда юлларны кардан чистарту;
3. ясалма тигезсезлек урнаштыру;
4. санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү буенча хезмәтләр;
5. су скважинасы өчен насос сатып алу. » - дигән сорау каралды һәм йомгаклау беркетмәсе төзелде

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 71 граждан кертелгән,

гражданнар җыенында катнашучылар һәм тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны саны 42 граждан.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" - 42 граждан тавыш бирде;

"ЮК" - 0 граждан.

Бәян ителгәннәр нигезендә,  гражданнар җыены **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлегенең Татар Сарсазы авылында гражданнар җыенын узган  дип танырга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Песәй авылы җирлегенең Татар Сарсазы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә,  I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, карамагында  балигъ  булмаган күп  балалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия армиясенә хәрби хезмәткә чакырылганнардан 500 сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итәргә  һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

1. вак таш сатып алу (китерү, тигезләү);
2. кышкы чорда юлларны кардан чистарту;
3. ясалма тигезсезлек урнаштыру;
4. санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү буенча хезмәтләр;
5. су скважинасы өчен насос  сатып алу» ? сез ризамы дигән сорауга карарны танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru  һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Песәй авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге башлыгы В.И.Мөхаматгалеев